ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 79 2018 елның 6 феврале

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының азык-төлек иминлеген тәэмин итү һәм туклануын оештыру максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдән укучыларның туклануын оештыру тәртибе турындагы нигезләмәне яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р.Фәретдиновка йөкләргә.

А.Г.Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 6 нчы февраль
79 нчы номерлы
карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдән укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә, гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдәге балалар өчен кайнар туклану оештыру максатларында, түбәндәге категория укучыларга эшләнде:

- ятим балалар һәм опекага алынган балалар;
- инвалид балалар;
- Чернобыль АЭСдә булган авария нәтиҗәләрен бетерүчеләр гаиләләреннән балалар;
- Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменә бәйсез рәвештә 18 яшькә кадәр 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән балалар;
- җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган азкеремле гаиләләрдән булган балалар (Республика матди ярдәм үзәгенең Түбән Кама муниципаль районындагы 31 нче бүлеге реестры нигезендә);
- социаль якланмаган гаиләләрдән булган балалар (индивидуаль якын килү: авыр тормыш хәленә эләккән балалар; авыруның авыр формалары булган балалар; «Түбән Кама муниципаль районында «ВЕСТА» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» социаль ярдәм күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе үтенече).

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «71 нче күрү сәләте бозылган балалар өчен компенсацияләү төрендәге балалар бакчасы - башлангыч мәктәп» мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге балалар өчен муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 пункты нигезендә, 2 мәртәбә түләүсез туклану белән тәэмин ителә.

3. Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында санап үтелгән укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыру өчен гомуми белем бирү оешмаларында составына директор, укытучылар коллективы арасыннан укучыларның туклануын оештыру өчен җаваплы һәм ата-аналар комитеты вәкилләре кергән комиссияләр төзелә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә биш кеше булырга тиеш.

Комиссия уку елы башында һәм кирәк булган саен алга таба карый:

- әлеге Нигезләмәнең 1, 2, 3 нче кушымталары нигезендә тапшырылган гаризаларны;

- Татарстан Республикасы законнары, җан башына уртача керемнәре яшәү минимумыннан түбәнрәк булган балалы гаиләләргә каралган социаль ярдәм чараларына Түбән Кама муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары нигезендә хокукы булган Түбән Кама муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнар турында «Компенсация түләүләре» республика матди ярдәм үзәгенең 31 нче бүлегеннән тәкъдим ителгән реестры һәм укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә;

- социаль яклanмаган гаиләләрдәге балаларны, аларның торак шартларын тикшерә, аларның матди хәлен, гаиләдәге балалар һәм асрамалар санын билгели, укучыларны өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗлар исемлегенә кертү турында карар кабул итә, тикшерү нәтиҗәләре белән беррәттән әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә актта терки;

- категорияләр буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның исемлекләрен раслый;

- сыйныф җитәкчесе яисә озайтылган көн төркеме тәрбиячесе җитәкчелегендәге ашханәдә укучыларның төркем белән йөрү графигын эшли;

- тәкъдим ителгән төшке ашларның билгеләнгән тәртиптә расланган менюга туры килүен тикшерә.

Комиссия хокуклы:

- кагыйдә бозулар белән әзерләнгән ризыкны сатудан төшерергә;

- медицина хезмәткәре белән берлектә китерелгән азык-төлекнең туры килүен тикшерергә, үлчәүне тикшереп торырга һ.б.

- тикшерүләр нәтиҗәләре буенча хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрүне белем бирү оешмасыннан таләп итәргә.

6. Сыйныф җитәкчеләре:

- ата-аналардан яисә аларны алмаштыручы затлардан түләүсез туклану өчен гариза алалар;

- гаризаларны алган көннән соң өч көн эчендә комиссия каравына җибәрәләр;

- категорияләр буенча сыйныфта укучыларның тукלануын исәпкә алалар;

- укучылар һәм ата-аналар арасында укучыларны тукландыру зарурлыгы турында аңлату эшләре алып баралар;

- барлык сыйныф укучыларының ашханәгә баруын контрольдә тоталар;

- ашханәдә туклану өчен «Мәктәп туклануы» модуле аша түләгәндә, «Мәктәп картасы»н куллану буенча сыйныф укучыларына аңлаталар яки кирәк булганда ярдәм күрсәтәләр.

7. Ата-аналар яки аларны алыштыручылар тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы.

8. Гомуми белем бирү оешмалары директорлары:

8.1.Комиссия беркетмәсе нигезендә, категорияләр буенча укучыларны түләүсез туклану белән тәэмин итүгә боерык чыгаралар.

8.2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы базасына кертү өчен мәгариф идарәсенә укучылар исемлекләрен тәкъдим итәләр.

9. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе укучыларының туклануын оештыру, азык әзерләү технологиясен үтәү, гомуми белем бирү оешмаларына чыгып, азык-төлек нокталарында чыгыш һәм санитария нормаларын үтәү мәсьәләләрен җитәкли.

10. Әлеге Нигезләмә үз гамәлләрен Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларына тарата.

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдән укучыларның туклануын оештыру тәртибенә
1 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәренең №___ мәктәп укучыларын тукландыруны оештыру комиссиясенә

_________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.О.)

_________________________________
(адресы)

гариза.

____________ сыйныфы укучысы улым (кызым, тәрбиягә алынучы)
_________________________________________________________________________
(Ф.И.А.ис.)
бушлай тукланугa рөхсәт бирүегезне үтенәм.
Нигез _________________________________________________________.
карар, ВТК белешмәсе, ташламаны раслый торган документлар

Өстәмә хәбәр итәм: ______________________________________________
_________________________________________________________________________.

Раслый торган документларны терким.

____________________
(Дата, имза)

--------------------------------
Гаризага беркетелә:
1. Гаилә составы турында белешмә.
2. Опека һәм попечительлек бүлегеннән белешмә яки балигъ булмаган балага опека билгеләү турындагы күрсәтмәнең күчермәсе.
3. Инвалид балалар өчен МСЭ медицина белешмәсенең күчермәсе.
4. Чернобыль АЭСындагы авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы таныклыгы күчермәсе.
5. Баланың туу турында таныклыгы.

Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында социаль яктан якланмаган гаиләләрдән укучыларның туклануын оештыру тәртибенә
2 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәренең №___ мәктәп укучыларын туклапдыруны оештыру комиссиясенә

____________________________________
(гариза бируче Ф.И.О.)

____________________________________
(адрес)

гариза.

___________ сыйныфы укучысы улым (кызым, тәрбиягә алынучы) ________________________________________________________________________________,
(Ф.И.А. ис.)

бушлай туклануга рөхсәт бирүегезне үтенәм.

Нигез ___________________________________________________________.
күпбалалы гаилә турында таныклык күчермәсе

Өстәмә хәбәр итәм: __________________________________________________
________________________________________________________________________________.

Раслый торган документларны терким.

______________________
(Дата, имза)

--------------------------------

Гаризага беркетелә:

1. Гаилә составы турында белешмә.

2. Күпбалалы гаилә турындагы таныклыкның күчермәсе.

3. Баланың туу турында таныклыгы күчермәсе (18 яшькә кадәрге барлык балалар).

4. 18-24 яшьлек балаларның, көндезге форма буенча укуын күрсәтеп, уку урыныннан белешмә.

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында
социаль яктан якланмаган гаиләләрдән
укучыларның туклануын оештыру
тәртибенә
3 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәренең №___ мәктәп
укучыларын тукландыруны оештыру
комиссиясенә

____________________________________
(гариза бируче Ф.И.О.)

____________________________________
(адрес)

гариза.

______________ сыйныфы укучысы улыма (кызым, тәрбиягә алынучы) _________________________________________________________________________
(Ф.И.А.ис.)

бушлай туклануга рөхсәт бирүегезне үтенәм.

Нигезе Җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк.

Өстәмә хәбәр итәм: _________________________________________________
_________________________________________________________________________.

Раслый торган документларны терким.

______________________
(Дата, имза)

--------------------------------

Гаризага беркетелә:

1. Баланың туу турында таныклыгы күчермәсе

Түбән Кама муниципаль районы
гомуми белем бирү оешмаларында
социаль яктан якланмаган гаиләләрдән
укучыларның туклануын оештыру
тәртибенә
4 нче кушымта

(Форма)

Түбән Кама шәһәренең______ мәктәбе ______ сыйныфы укучысы
Ф.И.А.ис. ________________________
гаиләсен тикшерү
АКТЫ

Түбән Кама шәһәре ___________20___ел.

Гаилә _____________________________________________________________________
(тулы булмаган, күпбалалы, социаль авыр хәлдә)
_________________________________________________________________________
бүлмәләр саны, мәйданы, уңайлыклары булу,
________________________________________адресы буенча фатирда (йортта) яши.
коммуналь, тулай торак, аренда)

Гаиләдә укучылар саны _____, гаиләдә асрамалар саны ______.
Гаиләнең матди хәле _____________________________________________.
(яхшы, урта, уртачадан түбән)

Гаилә әгъзасына гомуми керем _____ сум (ата-ана гаризасы буенча).
Ата-аналарның эш урыны, биләгән вазыйфасы, уртача айлык хезмәт хакы:
_______________________________________________________________________
Өстәмә белешмәләр: __________________________________________________
_________________________________________________________________________.

Гаиләнең торак шартларын һәм гаиләнең матди хәлен тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия карар кабул итә: ______сыйныфы укучысы
_________________________________________________________________
(Ф.И.О.)

өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ (мохтаҗ түгел).
(сайлап ал)

Комиссия рәисе: __________________________ ______________________
(имза, дата) (Ф.И.А.ис.)

Комиссия әгъзалары: ______________________ ______________________
(имза, дата) (Ф.И.А.ис.)

Сыйныф җитәкчесе: __________________________ ______________________
(имза, дата) (Ф.И.А.ис.)